РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июня 2023 ел г. Альметьевск № 1974

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе структурасын үзгәртү, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесенә кушу юлы белән «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәдәният идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесен үзгәртеп оештыру турында» 2023 елның 7 апрелендәге 846 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 июнендәге 1182 номерлы, 2020 елның 16 июлендәге 959 номерлы, 2020 елның 9 декабренге 1805 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 2448 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 пунктында һәм алга таба карарның барлык тексты һәм 1 нче кушымта буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәдәният идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

карарның 4 пунктындагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсе,» һәм «, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе» сүзләрен

Зак. № 305-2000

төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 7 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсенә караган 2023 елның 11 апреленнән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган нигезләмәләрдән тыш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А. А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов